АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**16.02.2021** **№ 7**

**Үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын үтәгән һәм коррупция куркынычы белән бәйле булган, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында**

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-701 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы» үтәү йөзеннән,

БОЕРАМ:

1. Үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын үтәгән һәм коррупция куркынычы белән бәйле булган, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары кушымта итеп бирелә торган Исемлекне расларга (алга таба – Исемлек).

2. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының юридик бүлегенә:

2.1. Эштән азат ителгәндә Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә карата «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясында каралган чикләүләрне, бурычларын һәм җаваплылыгын аңлатырга.

2.2. Әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының «Үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын үтәгән һәм коррупция куркынычы белән бәйле булган, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» 28.06.2009 елдагы 28 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 16.02.2021 № 7 боерыгы белән расланды

Үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын үтәгән һәм коррупция куркынычы белән бәйле булган, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары

**Исемлеге**

| № | Вазыйфаның атамасы | Вазыйфалар саны |
|---|---|---|
| | Җитәкчелек | |
| 1 | Җитәкченең беренче урынбасары | 1 |
| 2 | Җитәкче урынбасары | 2 |
| | Инвестиция проектларына экспертиза бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 2 |
| | Инвестицион проектларны алып бару һәм ярдәм итү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 1 |
| 3 | Әйдәп баручы консультант | 1 |
| | Мәгълүмат-аналитика бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Дәүләт хосусый партнерлыкны үстерү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Юридик бүлек | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Финанс исәбе һәм дәүләт сатып алулары бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | Беркетмә бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Инвестицияләрне җәлеп итү эшчәнлеген координацияләү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлекчәсе | |
| 1 | Бүлек мөдире | 1 |
| | Документлар белән тәэмин итү һәм контроль секторы | |
| 1 | Бүлек мөдире | 1 |
| | **Барлыгы:** | **19** |